**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 февралендәге 243 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 6 мартындагы 1462 номерлы «Хезмәт урыныннан бирелә торган торакларны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив-хокукый актны Россия Федерациясенең Торак һәм Гражданлык кодекларына туры китерү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 06 мартындагы 1462 номерлы «Хезмәт урыныннан бирелә торган торакларны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару тәртибе турында»гы карары кушымтасына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 21 июнендәге 4098 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 2167 номерлы, 2020 елның 3 апрелендәге 978 номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 486 номерлы, 2021 елның 13 октябрендәге 2584 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 3409 номерлы карарларын исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«- гариза бирүченең, аның гаилә әгъзаларының һәм алар белән бергә теркәлгән (2000 елның 1 гыйнварына кадәр туган) барлык гражданнарның даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу (булмау) турында техник инвентаризация органыннан белешмәләр»;

1.2. 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- әгәр мөрәҗәгать итүче зат нигезләмәнең 2.1, 2.2 пунктчаларында каралган гражданнар категориясенә карамаган булса;

- хезмәт урыныннан торак бирелгән гражданин яшәү өчен башка урынга күченеп киткән булса;

- әгәр мөрәҗәгать итүче гражданин һәм аның гаилә әгъзалары тарафыннан хезмәт урыныннан бирелгән торакны ниятле рәвештә муниципаль

махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару һәм шуның нәтиҗәсендә әлеге гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар дип танылырга мөмкин булган гамәлләр кылынган булса (бу очракта гражданнар әлеге алдан ниятләнгән эш башкарылган көннән алып биш елдан да иртәрәк булмаган вакытта хезмәт урыныннан бирелгән торакны муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан чыгару турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итә алалар)».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**